**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«31» октябрь 2022 ел Биклән авылы № 13

«Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 28 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган кушымтага үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты турында» нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 28 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 28 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә кертергә:

- авыл клубы бинасы.

2. Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Биклән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны «Якты юл» басмасында, шулай ук Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.Ш. Сәхбеев